**Республика Татарстан**
**Исполнительный комитет**
**Пестречинского**
**муниципального района**
422770, с. Пестрецы, ул. Советская, 18

**Татарстан Республикасы**
**Питрәч муниципаль**
**районы**
**башкарма комитеты**
422770, Питрәч авылы, Совет урамы, 18

тел. +7 (84367) 3-02-02 факс: (84367) 3-02-01 E-mail: pitriash@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«29» апрель, 2022 ел № 291

«Татарстан Республикасы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү территориаль системасының Питрәч звеносы турында» Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 18 декабрендәге 2393 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының үз көчләрен югалтуын тану турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 28 декабрендәге 1934 номерлы карарына туры китерү максатларында Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 18 декабрендәге 2393 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү территориаль подсистемасының Питрәч звеносы турында Положениегә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 1 нче кушымтаның 4 пунктындагы 3 абзацны яңа редакциядә бәян итәргә:

«объектлы дәрәҗәдә - гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссияләре, алар вәкаләтләренә халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау мәсьәләләре, шул исәптән су объектларында кешеләрнең куркынычсызлыгын тәэмин итү мәсьәләләре керә.»;

- 2 пунктта «халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә,» сүзләрен «халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау, шул исәптән су объектында кешеләрнең куркынычсызлыгын тәэмин итү,» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында http://pestreci.tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда http://pravo.tatarstan.ru Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткергәннән) соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Муниципаль район
Башкарма комитеты җитәкчесе А.В. Хәбибуллин